КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 август г.Казань № 741

2023 – 2025 елларга архив документларын саклауның бер берәмлеген тотуга чыгымнар нормативларын раслау турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына дәүләт милкенә караган архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм куллану өчен бирелә торган субвенция күләмен исәпләү өчен бер берәмлек архив документларын карап тотуга чыгымнар нормативын 2023 - 2025 елларга 12,65 сум күләмендә расларга.

2. 2023 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын раслау турында» 2020 ел, 2 сентябрь, 773 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Архив документларын саклауның бер берәмлеген карап тотуга чыгымнар нормативын раслау турында» 2020 ел, 2 сентябрь, 773 нче карарына үзгәреш кертү хакында 2021 ел, 06 сентябрь, 824 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин